**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«09» 08 2024 ел Яр Чаллы № 3620

«Җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә, муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетның 2022 елның 16 мартындагы 741 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә, муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетның 2022 елның 16 мартындагы 741 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8.2 пунктының 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясы 1 пункты 1 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеген шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирү турында белдерү басылып чыккан һәм урнаштырылган.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хабибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ * ИНН 1639031830